**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**«ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«30» май 2016 ел № 7/3

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Реклама турында» 13.03.2006 ел, № 38-ФЗ Федераль законның 10, 19 статьялары, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә,

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турында нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Тукай районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тоту законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе В.Г. Хаҗиев